


# “Әй, нәни кешем-өмет йолдызым”

(сәхнәләштерелгән тамаша)

Тәрбияче: Зарипова А.Р.

**Максат:**

- ***балаларда кечкенәдән үк әдәплелек, инсафлылык, мәрхәмәтлелек, ярдәмләшү хисләре һәм гадәтләре формалаштыру;***
- ***үзебезнең туган телгә мәхәббәт уяту;***
- ***балаларыбызны үз милләтебез рухында тәрбияләү, халкыбызның гореф-гадәтләренә күнектерү;***
- ***онытылмас бишек җырларын, такмакларын, бармак уеннарын өйрәтүне дәвам итү.***

Балалар идәндә түгәрәкләшеп уйнап утыралар. Уртада бишек тора. Әнкәй көйләп йон эрли (шул вакыт ишектән кыңгырау тавышы ишетелә).
Әнкәй. Туктагыз әле, балалар, кемдер килә ахры, кыңгырау чылтырый (ишекне ача). И Сания апа, әйдә түрдән уз. Ни хәлләрең бар?.
Сания апа. Рәхмәт. Үзегезнең хәлләрегез ничек? Исәнмесез, балалар.
Балалар. Исәнмесез!
Сания апа. Җанкисәккәйләрем, шушы оныгымны гына карап тора алмассызмы? Сәламәтләндерү үзәгенә барып кайтасым бар.
Әнкәй. Сания апага булышабызмы, балалар?
Балалар. Әйе.
Әнкәй. Әлбәттә карап торырбыз, Сания апа, борчылма. Тыныч кына йөреп кайт.
Сания апа. Ярар, алайса балалкайларым мин китим инде (чыгып китә).
Әнкәй. Балакайларым, хәзер мин сезгә Сания апаның оныгын күрсәтәм (баланы кулыны ала). Аның исеме Таңсылу.

**Таң кебек сылу кыз дигәнне аңлата аның исеме**
**Чынлап та аның исеме үзенә килешәме?**

Балалар. Әйе.
Әнкәй. Балакайларым, әйдәгез Таңсылу карап утырсын, ә без аңа үзебезнең белгән уеннарыбызны уйнап күрсәтәбез. Беренче бармак уеннарыннан башлыйбыз.

**“Йодрык” уенын уйнарбыз.**
**Уң кулыбызны табыйк**
**Әйдәгез, санап карыйк**
**Башлыйк чәнтидән**
**Иң кечтекидән**
**Чәнти була-бер,**
**Исемсез-ике,**
**Урта бармак-өч,**
**Имән бармак дүрт**
**Бишенчесе-баш бармак**
**Әнә ниндә зур тармак,**
**Менә биш күпме була**
**Бөкләгәч йодрык була.**

Әнкәй. Булдырдыгыз, балалар. Ягез әле тыңлап карыйк, тагын нинди бармак уеннары беләбез без.
**МИНДИЯР:** Уен “Кайда булдың”

Бармак, бармак,
Кайда булдың?
Бу абый белән
Урманга бардым.
Бу абый белән
Кырда йөрдем.
Бу абый белән
Ботка ашадыми.
Бу энем белән

Жыр жырладым.

<u>Әнкәй.</u> Рәхмәт, үскәнем. Ятагын кемне тыңлыйбыз.

**ТАҢСЫЛУ:** Уен "Бу бармагым..."

Бу бармагым- бабаем
Бу бармагым- әбием
Бу бармагым- әтием
Бу бармагым- әнием
Бу бармагым- мин үзем
Минем исемем- Таңсылу.

<u>Әнкәй.</u> Рәхмәт балам. Тагын кемнең уйныйсы килә.

**ЗӨЛӘЙХА.** Уен "Уенчыклар"

Бабай алды барабан.
Әби алды бөтерчек.
Әти алды машина.
Әни алды сипкергеч
Ә мин алам да зур туп
Уйныйм тупны сикертеп.

<u>Әнкәй.</u> Ай, рәхмәт. Без бик күп уеннар беләбез. Ә хәзер әйдәгез бергә "Без, без, уенын уйнап алабыз".

**БЕРГӘ.**

**Без унике кыз идек**
**Базга төштек бал ашадык**
**Келәтекә кердек бал таптык**
**Бер тактага тезелдек,**
**Ам-йом авызыңны йом.**

<u>Әнкәй.</u> Карагыз әле, балалар, Таңсылу арган ахры. Аның йоклыйсы килә. Әйдәгез без аны бишек җырлары җырлап йоклатабыз.

**МИНДИЯР.** Кошлар кунган тирәккә
Аларны җил тибрәтә
Тышта җилләр искәндә
Бәби йоклый бишектә.

**ТАҢСЫЛУ.** Әлли-бәлли бәбкәсе,
Кая киткән әнкәсе.
Каенлыкка җиләккә,
Үз кызына бүләккә.

**ЗӨЛӘЙХА.** Әлли-бәлли итәргә,
Ал бишеге бар аның.
Елаганда йоклатырга,
Үз әнкәсе бар аның.

**БЕРГӘ.** **Әлли-бәү, әлли-бәү,**
**Әлли бәлли бәлли бәү.**

<u>Әнкәй.</u> Балалар, Таңсылу чынлап та йокыга китте. Ул йокласын, ә без уеннарыбызны дәвам иттерик. Утырып аргансыздыр, әйдәгез түгәрәктә күңел ачып алабыз.

<u>Әнкәй.</u> **И, балалар, карагыз,**
**Тышта әнә килгән яз.**

Балалар. **Әйе, әйе, күрәбез**
**Яз килгәнен беләбез.**
Әнкәй. **Я, әйтегез, сөйләгез**
**Ничек килә икән яз.**
Балалар. **Кошлар кайтаерактан,**
**Җылы яктан көньяктан.**
(Кошлар очкан кебек хәрәкәтләр ясыйлар).
**Тып-тып тама тамчылар,**
**Әйтерсең лә камчылар.**
(уч төпләрендә тамчы тамганын күрсәтәләр)
**Елгалардан бозлар ага,**
**Диңгез ягына таба.**
(кулларын болгап күрсәтәләр)
**Кояш нурларын сибә,**
**Шундый күңелле безгә.**
(кул чукларын алыштырып җилпиләр)
**Сөенешеп йөрибез,**
**Көн саен бакчага без.**
(сикереп кулларын тотынышып әйләнәләр)
Әнкәй. Булдырдыгыз, балалар! Хәзер урыннарыгызга утырыгыз. Безнең Таңсылуны да уятырга вакыт җиткән. Без аны иркәләп уятыйк әле.
(Бер бала чыгып, курчакны сыпырып такмаклый, калганнар кушыла).
**Әйдә, кызым тор инде,**
**Йокын туйгандыр инде,**
**Казларыбыз су буеннан**
**Кайта торгандыр инде.**
**Әйдә, кызым тор инде.**
Әнкәй. Рәхмәт, кызым! (курчакны кулына ала). Әйдәгез, балалар, Таңсылуның күңелен күтәреп алыйк әле.
**“Үчтеки сикертик”**
**Балалар әйтә (әнкәй сикертә).**
**Үчтеки, үчтеки**
**Үсмәгәнгә кечтеки.**
**Үсәр эле зур булып**
**Менә дигән кыз булып.**
(кыңгырау шалтырый, Сания апа күренә).
Сания апа. Бигрәк яхшы балалар булып чыктыгыз әле сез. Юлым унды, рәхмәт сезгә. Еламадымы минем кызым?
Әнкәй. Юк, Сания апа без аның белән бик күңелле уйнадык.
Сания апа. Бигрәк әйбәт, игелекле балалр икәнсез. Ярый алайса без киттек инде, төшке ашка аш әзерлисем бар. Сау булыгыз, җаныйларым (чыгып китә).
Әнкәй. Менә, балалар без бүген нинди изге эш эшләдек. Үзебезгә дә күңелле булды. Өйрәнгән уеннарны, бишек җырларын искә төшердек. Сез аларны онытмагыз, иптәшләрегез белән уйнагыз. Әниләрегез дә сезне иркәләп йоклатсыннар. Иркәләп уятсыннар. Ягымлы һәм бәхетле балалар булыгыз.









